СОВЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 23, с. Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 23 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366)3-92-40, факс (84366)3-92-40. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**
**Апаз авыл җирлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**“25” октябрь 2021 ел** **№ 2**

**Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Кызыл-Игенче авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Апаз авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Кызыл-Игенче авылында Кызыл-Игенче авылы, Ерак урам, 3 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2021 елның 8 ноябренә 13 сәгать 00 минутта халык җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Кызыл-Игенче авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 1000 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан 2000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Кызыл-Игенче авылының Ерак урамыннан Пөшәңгәр авылының Тау өсте урамына кадәрге җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлын вак таш җәеп тигезләү, икенче этабы?

“ӘЙЕ” “КАРШЫ””

3. Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Кызыл-Игенче авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Апаз авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Кызыл-Игенче авылы, Ерак урамы, 16 йорты адреслары буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Котдусов